# КАРАР

**18 декабрь 2022 ел** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

а) беренче абзацта " 950 сум» сүзләрен «1600 сум»сүзләренә алмаштырырга

б) киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә:

- Байлангар авылы мәдәният йортына мебель, тамашачылар залы өчен урындыклар, музыка һәм спорт инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру, пәрдәләр, челтәрләр, сәхнә һәм театр пәрдәләре сатып алу һәм урнаштыру ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 521 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 270.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 268 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

а) беренче абзацта " 950 сум» сүзләрен «1600 сум»сүзләренә алмаштырырга

б) киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә:

- Байлангар авылы мәдәният йортына мебель, тамашачылар залы өчен урындыклар, музыка һәм спорт инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру, пәрдәләр, челтәрләр, сәхнә һәм театр пәрдәләре сатып алу һәм урнаштыру ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин

ОГРН 1021607752814
ИНН 1623001621